ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 сентября 2017 года

**Статья 1**

Внести в Бюджетный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II часть), № 10 (I часть), № 12 (IV часть); 2006, № 6 (I часть), № 12 (I часть); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III часть), № 10 (I часть); 2009, № 7 – 8 (I часть), № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 11 (I часть), № 11 (II часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 7, № 10, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 12 (III часть); 2015, № 7 (I часть), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (I часть) следующие изменения:

1) в статье $20^1$:

а) в абзаце втором пункта 1 слова «на праве оперативного управления у государственных учреждений и государственных унитарных предприятий, или» заменить словами «на праве оперативного управления у государственных учреждений либо на праве оперативного управления или хозяйственного ведения у государственных унитарных предприятий, а также»;

б) дополнить пунктом $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. Заключение и исполнение от имени Республики Татарстан государственных контрактов от лица органов государственной власти (государственных органов), являющихся государственными заказчиками, при осуществлении бюджетных инвестиций в объекты капитального строительства (за исключением бюджетных инвестиций в целях реконструкции, в том числе с элементами реставрации, технического перевооружения указанных объектов), которые будут находиться в государственной собственности, в соответствии с решениями, указанными в пунктах 2 и 3 настоящей статьи, могут осуществляться государственными корпорациями (компаниями), публично-правовыми компаниями в случаях, определенных федеральны-

ми законами (за исключением федерального закона о федеральном бюджете), иными нормативными правовыми актами о создании публично-правовых компаний, путем передачи на безвозмездной основе на основании соглашений полномочий государственного заказчика.

Созданные в результате осуществления бюджетных инвестиций объекты капитального строительства, указанные в абзаце первом настоящего пункта, закрепляются в установленном порядке на праве оперативного управления за государственными учреждениями либо на праве оперативного управления или хозяйственного ведения за государственными унитарными предприятиями с последующим увеличением стоимости основных средств, находящихся на праве оперативного управления у государственных учреждений либо на праве оперативного управления или хозяйственного ведения у государственных унитарных предприятий, а также увеличением уставного фонда указанных предприятий, основанных на праве хозяйственного ведения, в соответствии с решениями, указанными в пунктах 2 и 3 настоящей статьи.

Полномочия государственного заказчика могут быть переданы исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан, являющимися государственными заказчиками, юридическим лицам, акции (доли) которых принадлежат Республике Татарстан, при осуществлении бюджетных инвестиций в объекты капитального строительства государственной собственности с последующей передачей указанных объектов в качестве вклада в уставные (складочные) капиталы таких юридических лиц в соответствии с решениями, указанными в пунктах 2 и 3 настоящей статьи. Указанные решения должны содержать информацию о юридических лицах, которым передаются полномочия государственного заказчика.

Передача объектов капитального строительства в качестве вклада в уставные (складочные) капиталы юридических лиц, указанных в абзаце третьем настоящего пункта, влечет возникновение права государственной собственности на эквивалентную часть уставных (складочных) капиталов указанных юридических лиц, которое оформляется участием Республики Татарстан в уставных (складочных) капиталах таких юридических лиц в соответствии с гражданским законодательством Российской Федерации. Оформление доли Республики Татарстан в уставном (складочном) капитале, принадлежащей Республике Татарстан, осуществляется в порядке и по ценам, которые определяются в соответствии с законодательством Российской Федерации.

При передаче государственным корпорациям (компаниям), публично-правовым компаниям или иным юридическим лицам полномочий, предусмотренных настоящим пунктом, на них распространяются положения, установленные пунктом 4 настоящей статьи для бюджетных и автономных учреждений, государственных унитарных предприятий.»;

2) в пункте 1 статьи $20^{1.2}$ слова «на праве оперативного управления у этих учреждений и предприятий, или» заменить словами «на праве оперативного управления у этих учреждений либо на праве оперативного управления или хозяйственного ведения у этих предприятий, а также»;

3) в абзаце втором пункта 2 статьи $20^{1.3}$ слова «нормативными правовыми», «, а также за счет бюджетных ассигнований Инвестиционного фонда Республики Татарстан в соответствии со статьей $55^{3}$ настоящего Кодекса» исключить;

4) в пункте 3 статьи 25:

а) в абзаце втором слова «Инвестиционного фонда Республики Татарстан,», «соответственно на реализацию в текущем финансовом году проектов за счет средств Инвестиционного фонда Республики Татарстан,» исключить;

б) в абзаце четвертом после слов «оплате в отчетном финансовом году,» дополнить словами «бюджетных ассигнований на предоставление из бюджета Республики Татарстан местным бюджетам субсидий, субвенций и иных межбюджетных трансфертов, имеющих целевое назначение, предоставление которых в отчетном финансовом году осуществлялось в пределах суммы, необходимой для оплаты денежных обязательств получателей средств местного бюджета, источником финансового обеспечения которых являлись указанные межбюджетные трансферты, бюджетных ассигнований на предоставление субсидий юридическим лицам, предоставление которых в отчетном финансовом году осуществлялось в пределах суммы, необходимой для оплаты денежных обязательств получателей субсидий, источником финансового обеспечения которых являлись указанные субсидии,»;

5) статью 44 дополнить пунктом $7^{1}$ следующего содержания:

«$7^{1}$. В соответствии с законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан территориальному органу Федерального казначейства могут быть переданы на основании решений главных распорядителей средств бюджета Республики Татарстан полномочия получателя средств бюджета Республики Татарстан по перечислению межбюджетных трансфертов, предоставляемых из бюджета Республики Татарстан местному бюджету в форме субсидий, субвенций и иных межбюджетных трансфертов, имеющих целевое назначение, в пределах суммы, необходимой для оплаты денежных обязательств по расходам получателей средств местного бюджета, источником финансового обеспечения которых являются такие межбюджетные трансферты, в порядке, установленном Федеральным казначейством.»;

6) статью $44^{4}$ дополнить пунктом 5 следующего содержания:

«5. Заключение соглашений о предоставлении субсидий местным бюджетам из бюджета Республики Татарстан на срок, превышающий срок действия утвержденных лимитов бюджетных обязательств, осуществляется в случаях, предусмотренных нормативными правовыми актами Кабинета Министров Республики Татарстан, в пределах средств и на сроки, которые установлены указанными актами.»;

7) в статье 49:

а) абзац семнадцатый признать утратившим силу;

б) в абзаце двадцать пятом слова «получателей бюджетных средств, а также» исключить;

в) в абзаце тридцать третьем слова «бюджетов», «соответственно» исключить;

г) абзац тридцать седьмой изложить в следующей редакции:

«осуществляет методологическое руководство подготовкой и устанавливает порядок формирования и представления главными распорядителями средств бюджета Республики Татарстан (главными администраторами источников финансирования дефицита бюджета Республики Татарстан) обоснований бюджетных ассигнований по расходам (источникам финансирования дефицита) бюджета Республики Татарстан, а также обеспечивает соблюдение главными распорядителями средств бюджета Республики Татарстан (главными администраторами источников финансирования дефицита бюджета Республики Татарстан) соответствия обоснований бюджетных ассигнований по расходам (источникам финансирования дефицита) бюджета Республики Татарстан установленным требованиям;»;

8) в абзаце тринадцатом статьи $50^{1}$ слова «не позднее последнего рабочего дня текущего финансового года» исключить;

9) в подпункте 3 пункта 2 статьи 53 слова «политики Республики Татарстан и основных направлениях налоговой» заменить словами «и налоговой»;

10) статью $55^{3}$ признать утратившей силу;

11) в абзаце втором пункта 4 статьи 61 слова «политики Республики Татарстан и основными направлениями налоговой» заменить словами «и налоговой»;

12) в пункте 3 статьи 77:

а) абзац третий дополнить словами «, изменением подведомственности распорядителей (получателей) бюджетных средств и при осуществлении органами исполнительной власти Республики Татарстан бюджетных полномочий, предусмотренных пунктом 5 статьи 154 Бюджетного кодекса Российской Федерации»;

б) абзац четвертый дополнить словами «и (или) предусматривающих перечисление этих средств в счет оплаты судебных издержек, увеличения подлежащих уплате казенным учреждением сумм налогов, сборов, пеней, штрафов, а также социальных выплат (за исключением выплат, отнесенных к публичным нормативным обязательствам), установленных законодательством Российской Федерации»;

в) абзац восьмой изложить в следующей редакции:

«в случае получения уведомления о предоставлении субсидий, субвенций, иных межбюджетных трансфертов, имеющих целевое назначение, и безвозмездных поступлений от физических и юридических лиц сверх объемов, утвержденных законом Республики Татарстан о бюджете, а также в случае сокращения (возврата при отсутствии потребности) указанных межбюджетных трансфертов;»;

г) абзац девятый после слов «изменения типа» дополнить словом «(подведомственности)»;

13) в пункте 2 статьи $84^{1}$ слова «нарастающим итогом с начала текущего финансового года либо на соответствующий квартал» заменить словами «либо нарастающим итогом с начала текущего финансового года»;

14) пункт 2 статьи 93 изложить в следующей редакции:

«2. Субсидии, субвенции, иные межбюджетные трансферты, имеющие целевое назначение (в случае получения уведомления об их предоставлении), в том числе поступающие в бюджет в порядке, установленном Бюджетным кодексом Российской Федерации и пунктом 4 статьи 97 настоящего Кодекса, а также безвозмездные поступления от физических и юридических лиц, фактически полученные при исполнении бюджета Республики Татарстан сверх утвержденных законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан доходов, направляются на увеличение расходов бюджета Республики Татарстан соответственно в целях предоставления субсидий, субвенций, иных межбюджетных трансфертов, имеющих целевое назначение, с внесением изменений в сводную бюджетную роспись без внесения изменений в закон Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на текущий финансовый год и плановый период.»;

15) в абзаце третьем пункта 1 статьи 100 после слова «коду» дополнить словами «вида расходов».

**Статья 2**

Признать утратившими силу:

1) абзац одиннадцатый пункта 12 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 22 июня 2006 года № 46-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 6 (I часть); 2007, № 8; 2008, № 8 (III часть); 2013, № 10);

2) абзац девятнадцатый пункта 48 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 2 августа 2007 года № 38-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 8; 2009, № 1, № 7 – 8 (I часть); 2010, № 7 (II часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 7, № 10; 2014, № 12 (III часть);

3) пункт 21 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 22 июля 2013 года № 70-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан и Закон Республики Татарстан «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 7).

**Статья 3**

Установить, что положения пункта $4^1$ статьи $20^1$, подпункта 3 пункта 2 статьи 53, абзаца второго пункта 4 статьи 61 Бюджетного кодекса Республики Татарстан (в редакции настоящего Закона) применяются при составлении и исполнении бюджета Республики Татарстан начиная с бюджета Республики Татарстан на 2018 год и на плановый период 2019 и 2020 годов.

**Статья 4**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2018 года, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлен иной срок вступления их в силу.

2. Подпункт «б» пункта 1, пункт 3, подпункт «а» пункта 4, пункты 6, 8 – 12, 14 статьи 1, пункт 3 статьи 2 и статья 3 настоящего Закона вступают в силу со дня официального опубликования настоящего Закона.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
30 сентября 2017 года
№ 70-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына
үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $20^1$ статьяда:

а) 1 пунктның икенче абзацында “дәүләт учреждениеләренең һәм дәүләт унитар предприятиеләренең оператив идарә итү хокукындагы төп чаралар бәясен яисә” сүзләрен “дәүләт учреждениеләренең оператив идарә итү хокукындагы йә дәүләт унитар предприятиеләренең оператив идарә яисә хуҗалык алып бару хокукындагы төп чаралар бәясен, шулай ук” сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

“$4^1$. Татарстан Республикасыннан дәүләт заказчылары булып торучы дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары) исеменнән, дәүләт милкендә булачак капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен (күрсәтелгән объектларны реконструкция максатларындагы, шул исәптән реставрация элементлары белән, техник тәэмин итү максатларындагы бюджет инвестицияләреннән тыш) гамәлгә ашырганда, дәүләт контрактларын төзү һәм үтәү әлеге статьяның 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән карарлар нигезендә федераль законнар (федераль бюджет турындагы федераль законнан тыш), гавами-хокукый

компанияләр төзү турында башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән очракларда, килешүләргә таянып, дәүләт корпорацияләре (компанияләре), гавами-хокукый компанияләр тарафыннан түләүсез нигездә дәүләт заказчысы вәкаләтләрен тапшыру юлы белән башкарылырга мөмкин.

Бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектлары билгеләнгән тәртиптә оператив идарә итү хокукында дәүләт учреждениеләренә йә оператив идарә итү яисә хуҗалык алып бару хокукында дәүләт унитар предприятиеләренә беркетелә, алга таба дәүләт учреждениеләренең оператив идарә итү хокукындагы йә дәүләт унитар предприятиеләренең оператив идарә итү яисә хуҗалык алып бару хокукындагы төп чараларының хакы арттырыла, шулай ук әлеге статьяның 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән карарлар нигезендә хуҗалык алып бару хокукына нигезләнгән күрсәтелгән предприятиеләрнең устав фонды арттырыла.

Дәүләт заказчысы вәкаләтләре дәүләт заказчылары булып торучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт милкенең капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасына караган юридик затларга, әлеге статьяның 2 һәм 3 пунктларында каралган карарлар нигезендә күрсәтелгән объектларны алга таба мондый юридик затларның устав (тупланма) капиталларына кертем буларак биреп, тапшырылырга мөмкин. Күрсәтелгән карарларда дәүләт заказчысы вәкаләтләре тапшырыла торган юридик затлар турында мәгълүмат булырга тиеш.

Әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән юридик затларның устав (тупланма) капиталларына кертем буларак капиталь төзелеш объектларын тапшыру күрсәтелгән юридик затларның устав (тупланма) капиталларына туры килә торган өлешенә дәүләт милке хокукы барлыкка килүгә китерә, ул Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә мондый юридик затларның устав (тупланма) капиталларында Татарстан Республикасын катнаштырып рәсмиләштерелә. Татарстан Республикасына караган Татарстан Республикасы өлешен устав (тупланма) капиталында рәсмиләштерү Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган тәртиптә һәм бәяләрдә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт корпорацияләренә (компанияләренә), гавами-хокукый компанияләргә яисә башка юридик затларга әлеге пунктта каралган вәкаләтләрне тапшырганда, аларга әлеге статьяның 4 пунктында бюджет һәм автоном учреждениеләр, дәүләт унитар предприятиеләр өчен билгеләнгән нигезләмәләр дә кагыла.";

2) $20^{1.2}$ статьяның 1 пунктында "бу учреждениеләрдә һәм предприятиеләрдә оператив идарә хокукында булган төп чаралар бәясен яисә" сүзләрен "әлеге учреждениеләрдә оператив идарә итү хокукындагы йә әлеге предприятиеләрнең оператив идарә итү яисә хуҗалык алып бару хокукындагы төп чаралар бәясен, шулай ук" сүзләренә алмаштырырга;

3) $20^{1.3}$ статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында “норматив хокукый”, “„ шулай ук әлеге Кодексның $55^3$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Инвестиция фондының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән” сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 25 статьяның 3 пунктында:

а) икенче абзацта “Татарстан Республикасы Инвестиция фондының,”, “тиешенчә агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы Инвестиция фонды акчалары исәбеннән проектларны гамәлгә ашыруга,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта “бюджет ассигнованиеләренең” сүзләреннән соң “, хисап финанс елында җирле бюджет акчаларын алучыларның финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән бюджетара трансфертлар булган акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны бирүгә агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелгән максатчан юнәлештәге бюджет ассигнованиеләренең, хисап финанс елында финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән субсидияләр булган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелгән субсидияләрне юридик затларга бирүгә бюджет ассигнованиеләренең” сүзләрен өстәргә;

5) 44 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

“$7^1$. Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына таянып, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләрнең карарлары нигезендә Федераль казначылыкның территориаль органына җирле бюджетка Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган бюджетара трансфертларны җирле бюджет акчаларын алучыларның финанс белән тәэмин итү чыганагы шундый бюджетара трансфертлар булган чыгымнары буенча акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә Федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күчерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы вәкаләтләре тапшырылырга мөмкин.”;

6) $44^4$ статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

“5. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булган сроктан артыграк срокка субсидияләр бирү турында килешүләр төзү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында каралган очракларда, әлеге актларда күрсәтелгән акчалар чикләрендә һәм срокларга төзелә.”;

7) 49 статьяда:

а) унҗиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) егерме бишенче абзацта “бюджет акчаларын алучыларның, шулай ук” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) утыз өченче абзацта “тиешле” сүзен төшереп калдырырга, “бюджет керемнәре” сүзләрен “керемнәр” сүзенә алмаштырырга;

г) утыз җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр (Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары (кытлыкны финанслау чыганаклары) буенча бюджет ассигнованиеләрен нигезләүне әзерләүгә ысулый җитәкчелек итә, аны формалаштыру һәм тапшыру тәртибен билгели, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр (Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары) тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары (кытлыкны финанслау чыганаклары) буенча бюджет ассигнованиеләрен нигезләүнең билгеләнгән таләпләргә туры килүен тәэмин итә.”;

8) $50^1$ статьяның унөченче абзацында “агымдагы финанс елының ахыргы эш көненнән дә соңга калмыйча” сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 53 статьяның 2 пунктындагы 3 пунктчасында “Татарстан Республикасы бюджет сәясәтенең төп юнәлешләренә һәм Татарстан Республикасы салым сәясәтенең” сүзләрен “Татарстан Республикасы бюджет һәм салым сәясәтенең” сүзләренә алмаштырырга;

10) $55^3$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

11) 61 статьяның 4 пунктындагы икенче абзацында “Татарстан Республикасы бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм Татарстан Республикасы салым сәясәтенең” сүзләрен “Татарстан Республикасы бюджет һәм салым сәясәтенең” сүзләренә алмаштырырга;

12) 77 статьяның 3 пунктында:

а) өченче абзацта “дәүләт мөлкәтен тапшыруга” сүзләреннән соң “, бюджет акчаларын бүлүчеләрнең (алучыларның) ведомство буйсынуын үзгәртүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 154 статьясындагы 5 пунктында каралган бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда” сүзләрен өстәргә;

б) дүртенче абзацта “бюджет акчаларыннан түләтүне күздә тота торган” сүзләреннән соң “һәм (яисә) бу акчаларны суд чыгымнарын түләүгә, казна учреждениесе тарафыннан түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, пеняләр, штрафлар суммасын, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән социаль түләүләрне (гавами норматив йөкләмәләргә кергән түләүләрдән тыш) арттыруга күчерүне күздә тота торган” сүзләрен өстәргә;

в) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“бюджет турында Татарстан Республикасы законында расланган күләмнәрдән тыш максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара

трансфертлар бирү турында хәбәрнамә алынган, физик һәм юридик затлардан кире кайтарылмый торган керемнәрне алган очракта, шулай ук күрсәтелгән бюджетара трансфертларны кыскарткан (ихтыяҗ булмаганда кире кайтарган) очракта;";

г) тугызынчы абзацта "дәүләт учреждениеләренең" сүзләреннән соң "(ведомство буйсынуы)" сүзләрен өстәргә;

13) $84^1$ статьяның 2 пунктында "агымдагы финанс елы башыннан ай саен яисә квартал саен арта бара торган нәтиҗә белән" сүзләрен "ай саен яисә квартал саен йә агымдагы финанс елы башыннан арта бара торган нәтиҗә белән" сүзләренә алмаштырырга;

14) 93 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Татарстан Республикасы бюджетын үтәгәндә Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган керемнәрдән тыш фактта артыграк алынган максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар (аларны бирү турында хәбәрнамә алынган очракта), шул исәптән бюджетка Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодексның 97 статьясындагы 4 пунктында билгеләнгән тәртиптә керә торганнары, шулай ук физик һәм юридик затлардан кире кайтарылмый торган керемнәр, агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертмичә генә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертеп, максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында тиешенчә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын арттыруга җибәрелә.";

15) 100 статьяның 1 пунктындагы өченче абзацында "классификациясе кодына" сүзләрен "классификациясенең чыгымнар төре кодына" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) "Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2006 елның 22 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 8; 2008, № 8 (III өлеш); 2013, № 10) 1 статьясындагы 12 пунктының унберенче абзацын;

2) "Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 8; 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10; 2014, № 12 (III өлеш) 1 статьясындагы 48 пунктының унтугызынчы абзацын;

3) "Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм "Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2013 елның 22 июлендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7) 1 статьясындагы 21 пунктын.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $20^1$ статьясындагы $4^1$ пункты, 53 статьясындагы 2 пунктның 3 пунктчасы, 61 статьясындагы 4 пунктның икенче абзацы нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә 2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап кулланыла.

**4 статья**

1. Әлеге Закон, шушы статья белән үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының “б” пунктчасы, 3 пункты, 4 пунктындагы “а” пунктчасы, 6, 8 – 12, 14 пунктлары, 2 статьясының 3 пункты һәм 3 статьясы әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 30 сентябрь
№ 70-ТРЗ